ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы күләмен билгели.

2. Әлеге Закон максатларында “Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында” 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә сәнәгать сәясәте өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән федераль башкарма хакимияте органы яисә сәнәгать тармакларында махсус инвестиция контрактларын төзүгә Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән башка федераль башкарма хакимияте органы тарафыннан Россия Федерациясе исеменнән, шулай ук Россия Федерациясе белән бергә “Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында” 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән махсус инвестиция контракты ягы булып торучы инвесторлар махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар булып таныла.

2 статья. **Салым ставкалары**

1. Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен махсус инвестиция контрактында каралган инвестиция проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә җитештерелгән товарларны реализацияләүдән салым исәп-хисабы буенча беренче табыш алынган салым чорыннан башлап һәм махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогы тәмамланганчы, ләкин 2025 елдан да соң түгел